Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам Нуры

بسم الله الرحمن الرحيم

№ 13 (641) 7 июль, 2017 ел (1438, Шәүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+

## Шәһәр мэры Җәмигъ мәчете төзелеше белән танышты





**26** июньдә Чаллы мэры, шәһәрнең Җәмигъ мәчете попечительләре Шурасы рәисе Наил Гамбәр улы Мәһдиев Җәмигъ мәчете төзелеш барышы белән танышты. Бүгенге көндә мәчетнең цоколь катын төзүдә эшләүче “Стройтраст” фирмасы генераль директоры Раил Миннегалиев шәһәр башлыгына төзелеш объектының бүгенге торышы, төзелеш эшләренең ничек баруы турында сөйләде. Аның әйтүенчә, төзелеш график буенча алып барыла, сыйфат торышы даими тикшерелә. Төзүчеләрнең барсы да сайлап алынган, тәҗрибәле, тәртипле кешеләр. Цоколь каты монолит ысул белән төзелә. Быел аны төзеп бетерү, тышкы өлешен кызыл кирпич белән тышлау, гидроизоляция эшләрен башкару бурычы тора. Төзелешкә финанс ярдәме күрсәтү фонды җитәкчесе Уел Хәсәенов белдерүенчә, бүгенге көн өчен төп проблема булып кадрлар, төзелеш материаллары түгел, ә акча җитмәү тора. Цоколь катын тәмамлау өчен өстәмә рәвештә 15 млн. сум акча таләп ителә. Халык, спонсорлар моны аңлар, тиешле ярдәмне күрсәтерләр дигән ышаныч бар. Мэр җитәкчелегендә төзелешкә килгән кайбер попечительләр моны яхшы аңладылар.

Җәмигъ мәчете белән танышу вакытында Наил Гамбәр улын шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, аның урынбасары Фоат хәзрәт Мөхәммәтов, нәзарәтнең вакыф фонды вәкиле Фәрит Шәрипов, Уел Хәсәенов, төзелешкә бәйле башка рәсми кешеләр озатып йөрде.

## “Ак мәчет” мәдрәсәсендә чыгарылыш

**26** июньдә Чаллының “Ак мәчет” мәдрәсәсендә чираттагы чыгарылыш булды. 52 кеше көндезге, кичке, читтән торып уку бүлекләрен тәмамлады. Ошбу хакта мәдрәсә директоры, төбәк казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли болай ди: “52 кеше укуны уңышлы тәмамлады. Бүген аларга дипломнар тапшырабыз. Көндезе бүлекне тәмамлаучылар РИУга баралар. Кичке бүлекне тәмамлаучылардан имам булып китүчеләр бар. Хатын-кызларның бөтенесе дә диярлек якшәмбе мәктәпләрендә укытучылар булачаклар. Бүгенге көндә Чаллы мәчетләрендә дин дәресләре бирүче мөгаллимәләр — алар безнең укучыларыбыз. Мәдрәсәбезне тәмамлаучыларның күпчелеге Татарстанның Көнчыгыш төбәгеннән. Шулай ук Башкортостаннан килеп укучылар да юк түгел.

Алдагы уку елына март аеннан башлап гаризалар кабул итү бара. Көндезге бүлектә уку 20 августта башлана, кичке бүлектә - октябрь аеннан. Ә читтән торып уку бүлегенә керүчеләр өчен беренче бер атналык сессияләр ирләр өчен октябрьнең беренче якшәмбесендә, хатын-кызлар өчен икенче якшәмбесендә башлана. Белешмәләр өчен тел. (8552) 38-67-02. Рәхим итегез!”



Мәдрәсәнең актлар залында чыгарылыш төркеме шәкертләре өчен күңелле тантана узды. Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли һәм шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин мәдрәсәне тәмамлаучыларга үгет-нәсихәтләрен җиткерделәр.



Дипломнар тапшырылгач кичәге шәкертләр мәдрәсә директоры, мөгаллимнәр адресына күп җылы сүзләр әйттеләр, рәхмәтләрен белдерделәр, бүләкләрен тапшырдылар. Аннары мәдрәсәне тәимамлаучылар хөрмәтенә аш мәҗлесе үтте.

Мәдрәсәне тәмамлаучыларның күпчелеге дөньяви югары белемгә дә ия.

**Рәсемнәрдә:** Рөстәм хәзрәт Тукай районы Иске Дөреш авылы имамы Әнвәр Галимҗановка диплом тапшыра; мәдрәсәне тәмамлаучы хатын-кызлар төркеме.

# ЙУНЫС ГАЛӘЙҺИССӘЛӘМ

Бүгенге вәгаземдә диңгез төбенә төшкән, бик авыр вакытта Аллаһы Тәгаләдән бер хикмәтле чишелеш килгән, беркем дә сәҗдә кылмаган җирдә сәҗдә кылган Йунус галәйһиссәләм турында сөйләргә телим.

Йунус пәйгамбәр Ягъкуб галәйһиссәләмнең улы, ягъни Йосыф галәйһиссәләмнең энесе Биниәминнең оныгы иде. Аллаһы Тәгалә аны Мусылә җирләренә, хәзерге Ирак территориясе, Нәйнәүә шәһәрендә яшәүче, потларга табынучы кавемгә пәйгамбәр итеп җибәрә. Хәзрәти Йунус галәйһиссәләм бу кавемне гаять зур сабырлык белән хак дингә, бер Аллаһка гыйбадәт кылырга өнди. Кызганычка каршы, күпме генә вәгазьләсә дә, бу кавемнең халкы аңа колак салмый, алар Йунус галәйһиссәләм чакырган хак динне кабул итмиләр.

Шуннан Йунус галәйһиссәләм: "Әгәр иман китермәсәгез, өч көн эчендә өстегезгә Аллаһтан газап киләчәк",- дип бу кавемне ташлап чыгып китә. Аллаһы Тәгалә бу турыда әйтә: "Ачуланып кавеменнән аерылып китте, ул уйлады кавемен ташлап киткән өчен Безнең аңа хөкем булмас дип."

Йунус галәйһиссәләм үз кавеменә хак динне кабул итмәгәннәре өчен бик ачулана һәм алары Аллаһы Тәгалә хөкеменә калдыра. Бу халык башта ышанмый. Өч көн булгач, күктә утлар күренә. Шул вакыт куркып, Йунысны эзләргә тотыналар, ләкин тапмыйлар. Инде бу кавем аңга килә, бик нык хаталанганнарын аңлап алалар. Йунус галәйһиссәләмнең пәйгамбәр икәненә ышаналар, бу халыкның һәммәсе, иман китереп, тәүбә итәләр. Аллаһы Тәгалә Үзенең хикмәте белән тәүбәгә килүне аларның йөрәкләренә, күңелләренә сала. Алар Йунус галәйһиссәләмгә гаделсезлек күрсәткәннәре өчен бик үкенәләр. Барча халык, хәтта кечкенә бәбиләре булган аналар да, сабыйларын күтәреп, бар булган терлек-хайваннарын куалап, ачык урынга чыгалар һәм төркем-төркем булып бүленәләр. Шулхәтле бирелеп тәүбә итәләр, тәүбәдән башка бернәрсә аларны борчымый, хәтта кычкырып-кычкырып елаган балаларының да тавышларына игътибар итмиләр. Барчасы: ирләр дә, хатыннар да, балалар да, хәтта хайваннарга кадәр Аллаһы Тәгаләгә иман китереп, елый-елый, Аллаһы Тәгаләдән кичерүен үтенергә тотыналар. Йөз мең кеше чамасы булалар. Күз алдына гына китереп карагыз әле, йөз мең кеше күзләреннән яшь агызып, тәүбәгә килеп, Аллаһы Тәгаләдән кичерүен сорый, Йунус галәйһиссәләмне тыңламаганнары өчен бик үкенәләр. Һәм Аллаһы Тәгалә аларны гафу итә.

Аллаһы Тәгаләнең җәзасы бик якын була, әмма Ул аларны Үзенең җәзасыннан коткара. Аллаһы Тәгалә бу турыда болай ди: "Йунус кавеменнән башка, һич бер кавемнең газапны күргәч кенә китергән иманнары файда бирмәде. Чөнки Йунус кавеме иман китергәч, алардан дөнья газабын бетердек вә әҗәлләре җиткәнче файдаландырдык."

Игътибар итик, Йунус (галәйһиссәләм) үз халкын иманга килмәс дип саный, хәтта аларга Аллаһы Тәгаләнең җәзасы киләчәк вакытны да билгеләп куя. Әмма Аллаһы Тәгалә аларның иманга килүен тели. Шуңа күрә, аңларга кирәк: бу дөньяда бар нәрсә Аллаһтан. Кешенең иманга килүе дә, килмәве дә. Карагыз, Йунус пәйгамбәр дә кавеменең кайчан да булса, иманга килүенә өметен өзгән, әмма Аллаһы Тәгалә бу кавемне иманга китергән. Бәлки әле, безнең арада да гаиләләре, ирләре, хатыннары, я башка туганнары, яисә якыннары иманга килмәгән кешеләр бардыр. Өметебезне өзмик, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте киң.

Шуннан Йунус пәйгамбәр башка җирләргә чыгып китү өчен, көймәгә утыра. Аллаһы Тәгалә бу турыда болай ди: "Һәм Йунус та Безнең җибәргән пәйгамбәрләребездәндер. Йунус иман китермәгән кавемен ташлап, кешеләр белән тулган зур көймәгә керде."

Диңгездә барганда бик нык давыл чыга. Көймә бату куркынычы туа. Шуннан көймәдәге бар авыр әйберне диңгезгә ташлыйлар. Бу да ярдәм итми. Көймәдәге кешеләр саны күп була, бату куркынычы туа. Чөнки бу хәтле кешене көймә күтәрә алмый. Инде кешеләрнең кайберсенә көймә батмасын өчен, ачык диңгезгә сикерергә туры килә. Шобага салалар. Шобага беренче тапкыр Йунус галәйһиссәләм чыга, шуннан тагын бер тапкыр шобага салалар, тагын Йунуска галәйһиссәләмгә чыга. Шуннан тагын бер тапкыр шобага салырга булалар, ул өченчесендә дә Йунус галәйһиссәләмгә чыга. Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә: "Ул башкалар белән бергә шобага сала, әмма оттыра,"- ди.

Беренче карашка инде үлеме килеп җиткән кебек. Әмма без еш ялгышабыз. Йунус галәйһиссәләмне көймәдән диңгезгә ташлаган вакытта яннарыннан бер кит узып бара һәм Аллаһы Тәгалә аңа Йунус галәйһиссәләмне йотарга боера.

Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ул шелтәгә лаек вакытта аны балык йотты."

Йунус галәйһиссәләм кит эчендә: "Инде үлдем",- дип уйлый. Аннан аякларын селкетеп карый, аяклары исән-сау, шуннан ул кит эчендә үзенең исән икәнен аңлап ала. Шунда ук торып Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кыла: "Йә Раббым, мин Сиңа моңарчы беркем гыйбадәт кылмаган җирдә сәҗдә кылам,"-ди.

Кит эчендә дөм караңгы була. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ул караңгылыктан мөрәҗәгать итте."

Йунус галәйһиссәләм өч кат караңгылык эчендә була. Беренчесе - кит эчендәге караңгылык, икенчесе - диңгез төбендәге караңгылык, өченчесе - төн караңгылыгы.

Үзебезне Йунус галәйһиссәләм урынында итеп күз алдына китереп карыйк. Ул кит эчендә. Анда шулхәтле караңгы, хәтта үзеңнең кул-аягыңны да күреп булмый, һәрвакыт юеш. Бу коточкыч зур кит, аны теләсә кайчан ашап бетерергә мөмкин. Ничек куркыныч!

Кит эчендә диңгез буйлап йөзгәндә Йунус галәйһиссәләм башка китларның Аллаһка зекер итүләрен, аннан да бигрәк, хәтта диңгез төбендәге ташларның да Аллаһка зекер итүләрен ишетә. Шунда Йунус галәйһиссәләм Аллаһка: «Йә Аллаһ, Синнән башка һич илаһ юк, мәгәр Син генә, Сине һәр кимчелектән пакь дип беләмен. Синең рәхсәтеңнән башка кавемемне ташлап китүем белән үземә золым итүчеләрдән булдым!» ди.

СөбхәнАллаһ, менә бу дога! Уйланыйк әле, Аллаһы Тәгаләне ничек югары күтәрә ул, үзенең нинди түбән хәлдә икәнен аңлый, хаталарын таный. Ул шулхәтле курка Аллаһы Тәгаләдән, хәтта кичерүен турыдан-туры сорарга ояла. Йә Аллаһ, мине кичер, коткар дими ул. Юк! Аллаһы Тәгаләне мактый! Зекерләрнең иң яхшысын, «лә иләһә иллә Аллаһ» тәүхид кәлимәсен әйтә, гөнаһ кылганына бик үкенә, тәүбә итә. Үз кавеменең кылганнарына түзә алмаганга, өметен өзгәнгә үкенә. Сабырлык белән үз кавеменең иманга килгәнен көтә алмаган, Аллаһы Тәгаләдән шушы сынау килүен аңлый ул.

Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итә: "Без аның догасын кабул иттек һәм аны кайгы- хәсрәттән имин кылдык. Без иман ияләрен шулай коткарачакбыз."

Шулай ук Аллаһ Тәгалә әйтә: "Әгәр ул тәсбих кылучылардан булмаган булса, Без аны кит корсагында Кыямәт көненә кадәр калдырыр идек."

Ягъни, бер Аллаһка табынганга, йөрәгендә бер Аллаһ булганга, Аллаһы Тәгалә аны коткара. Аллаһы Тәгалә: "Әгәр ул зекер итмәгән булса, Кыямәт көненә кадәр кит эчендә булыр иде,"- ди.

Ибн Джарир Тәбәри үзенең тәфсирендә болай ди: "Кит Йунысны йоткач, ул кит эчендә диңгез төбенә төшә. Анда ул бер тавыш ишетә, шуннан аптырап кала, нинди тавыш булырга мөмкин диңгез төбендә? Аллаһы Тәгалә аңа бу тавышның диңгездәге хайваннарның тәсбихе икәнен төшендерә. Шуннан Йунус галәйһиссәләм кит эчендә сөбхәнәАллаһ дип тәсбих әйтә башлый. Фәрештәләр бу тәсбихне ишетеп: "Йә, Аллаһ! Без бер дә ишетмәгән, гаҗәеп бер җирдән тавыш ишетәбез,"- диләр. Аллаһы Тәгалә аларга: "Бу минем колым Йунус, ул Мине тыңламады һәм Мин аны кит эченә бикләп куйдым,"- ди. Фәрештәләр Аллаһка: " Ул моңынчы көн дә, төн дә бер Сиңа гыйбадәт кылган хак колың бит,"- дип Аллаһтан аны коткаруын үтенергә тотыналар. Шуннан Аллаһы Тәгалә китка Йунысны яр буенда калдырырга куша.

СөбхәнәАллах! Бу Пәйгамбәребез бертуганының улына үгет- нәсихәт кылганда дәлилләнә: "Аллаһны сакла һәм Аллаһ та сине саклар, Аллаһны сакла һәм син Аны үз алдыңда итеп табарсың. Сиңа рәхәт чакта, Син имин чакта Аллаһны таны һәм Аллаһ сине авыр чакта таныр."

Башка тәфсирдә Аллаһы Тәгалә Йунус галәйһиссәләмне ул моңарчы Аллаһка гыйбадәт кылганы өчен коткарды диелә.

Шуңа күрә, кардәшем, яхшы эшләр эшләргә кирәклегенә җиңел карама. Бәлки, син биргән садака, яки тоткан уразаң, кешеләргә яхшы мөгамәләдә булуың, сине иң кирәк вакытта коткарыр.

Шуннан Аллаһы Тәгалә китка Йунус галәйһиссәләмне яр буенда калдырырга әмер бирә. Аллаһы Тәгалә бу турыда: "Без аны ачык урында ташладык һәм ул бик авырый башлый",- ди.

Балык эчендә байтак вакыт булган тәнне күз алдыгызга китереп карагыз әле. Ул көчсезләнә, зәгыйфьләнә, авырый. Бераз вакыт су эчендә утырсак та, тәнебезнең тиресе үзгәрә, бозыла башлый бит. Әмма Аллаһы Тәгалә аны бу авыр чакта ялгыз калдырмый, аны кайгырта, тәнен сихәтләндерә. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Без аның өстеннән яки аның янында кабак үстердек," -ди.

Һәм Йунус янында кабак агачы үсеп чыга, аны эссе кояштан һәм бөҗәкләрдән саклый.

Аллаһ Тәгалә Үзенең бәрәкәте белән аның тәнен тулысынча сихәтләндерә.

Шуның белән генә Аллаһы Тәгаләнең шәфкате бетәме соң? Юк, җәмәгать! Аллаһы Тәгаләнең бүләкләве турында сүз барганда, без аның күләмен күз алдына да китерә алмыйбыз. Бик күп, кадерле, кыйммәтле бүләкләү ул. Аллаһы Тәгалә Йунус галәйһиссәләмне үз кавемендәге барча кешеләрнең тәүбәгә килүе белән куандыра. Аллаһы Тәгалә бу турыда: "Без аны йөз меңгә, яки аннан да күбрәкләргә җибәрдек. Алар иман китерделәр һәм Без аларга билгеле бер вакытка кадәр нигъмәтләрдән файдаланырга рөхсәт иттек,"- ди.

Карагыз, ничек юмарт Аллаһы Тәгалә! Аллаһы Тәгалә Йунысны диңгездәге үлемнән, кит эчендәге авырлыклардан коткарып кына калмый, ә тәнен сихәтләндерә, хәтта кавемендәге бар халкының иманга килүе белән аны куандыра. Бу барыбызга да нәсихәт, дин кардәшләрем! Беркайчан да кешеләрнең иман китерүеннән өметебезне җуймыйк! Нихәтле генә кеше түбән тәгәрәмәсен, нихәтле гөнаһка чуммасын, читкә борылмыйк! Аллаһы Тәгаләдән авыр вакытта ярдәм көтәбез икән, рәхәт, яхшы чакта да, көчебез булганда да гыйбадәт кылыйк!

Йә, кардәшем! Әгәр син Аллаһтан нигъмәт көтәсең икән, исеңә төшер, үзең соң син соңгы тапкыр мохтаҗларга кайчан булыштың?...

Син Аллаһы Тәгаләдән авыр чакта ярдәм сорыйсың, ә үзең соң кайчан ярдәм иттең? Хәтта кемгәдер машинасын кабызырга булышу да, кемгәдер авыр сумкасын күтәрешеп бару да ярдәм бит!

Кадерле дин кардәшләрем, безнең мәчетебезгә ярдәм итүгез өчен бик зур рәхмәтемне белдерәм. Аллаһы Тәгаләдән ярдәмгә мохтаҗ вакытыгызда сезгә ярдәм итүен сорыйм.

Игътибар итик, Коръәндә диңгездә батучы ике кеше турында телгә алына. Аларның берсе Аллаһы Тәгаләнең дошманы, ә икенчесе Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәре. Аларның икесе дә Аллаһы Тәгаләгә дога кыла. Икесенең дә догасы күкләргә күтәрелә. Аллаһ дошманының догасы кабул булмый, һәм ул һәлак итеlә, түбәнсетелә. Ә Пәйгамбәрнең догасы кабул була. Догасы кабул булган Пәйгамбәр ул - Йунус, ә Аллаһның дошманы - Фиргәвен.

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы.**

*Укучыларыбыз иҗаты*

## Алмалы нәсыйхәт

Эштән кайтуга, Наилә каршына кечкенә кызы йөгереп чыкты.

– Әни-әни! Миңа әбием алма бирде! – дип ихлас елмаеп, сөенече белән уртаклашты Алсу һәм кулларын өскә чөеп, өстәп куйды: “Икене!”

Һәр кулына берәр алма тоткан нәни кыз әнисе тирәсендә сикергәли башлады. Наилә, шатлыклы елмаеп, шаярыбрак әйтеп куйды:

– Кызым, шул ике алманың берсен әниеңә бирмисеңме соң?

Әнисенә беравык карап торганнан соң, Алсу тиз генә башта бер алмасын тешләп алды, аннан, шулай ук ашыгып, икенчесен дә тешләде.

Наилә йөзендәге елмаюы сүнеп, күңеле көйсезләнеп китте. “И-и, кызым, кадерле әниең өчен бер алма да кызганычмы?” – дип уйлап куйды ул. Шулай да баласына дәшмәде, кәефе кырылганын күрсәтмәскә тырышты. Әмма бу вакытта бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Кечкенә Алсу бер алмасын әнисенә сузды да болай диде:

– Әнием, мә, монысын ал, бу алма тәмлерәк!

Наилә,калтырана башлавын тоеп, әкрен генә диварга сөялде. “Йә Алла... ничек тыелып калдым, ничек акыл өйрәтәм дип шелтәләмәдем баланы!” – дип уйлап куйды ул, йөрәге турысын тотып, һәм сабак булырлык бу хәлдән соң, хезмәттәше белән күптән түгел булган бер күңелсез вакыйганы исенә төшерде...

Ул чакта аның белән бер бүлмәдә эшләгән хатын, Наилә утырам дигәндә генә, урындыгын кинәт тартып алды. Шуңа ачуы чыгып, Наилә хезмәттәшен кычкырып әрләде. Баксаң, шул урындыкка ул ялгыш чәен түккән икән һәм Наиләне киемен чылатмасын дип алып куймакчы булган. Әмма ул вакытта Наилә сабырсызланып дәгъва белдерде, шуның аркасында хезмәттәше белән ара суынды. Әле хәзер дә үч алырга теләгәндәй ара тупас дәшә бит ул... “Иртәгә үк гафу үтенәм!” – дип ниятләп куйды Наилә. Аннары кызы сузган алманы алды да, яшьләнгән күзләре белән баласына ягымлы карап, хисләнеп әйтте:

– И кызым, рәхмәт инде сиңа, зур рәхмәт! Алма өчен дә, барысы өчен дә бик зур рәхмәт сиңа, балакаем!

**Ришат хәзрәт Курамшин.**
**Кукмара шәһәре.**

*Хикәят*

## Хәерсез байлык

Аллаһы Тәгалә әйтә: “Алар арасында: “Әгәр Ул безгә юмартлыгыннан бирсә, әлбәттә, без садака бирербез һәм изгеләрдән булачакбыз,”- дип Аллаһ белән килешү төзегәннәр дә бар. Ә аларга Аллаһ Үзенең юмартлыгыннан биргәч, алар саранланды һәм читкә китеп йөз чөерде” (9:75-76).

Ошбу аять Сәләбә ибн Хәтимә әл Әнсарга карата төшерелә. Сәләбә көн-төн пәйгамбәребез (с.г.в.) мәчетендә була. Ягъни гаиләсендә булган вакытны исәпкә алмаганда. Шуңа күрә аны “мәчет күгәрчене” дип атыйлар. Күп мәртәбәләр сәҗдә кылудан аның мангае дөя тезенә охшап кала.

Күпмедер вакыттан соң Сәләбә мәчеттән пәйгамбәребез (с.г.в.) иртәнге намазны тәгалләү белән тәсбихне һәм доганы көтмичә китә башлый. Моны күреп Аллаһы илчесе аңа әйтә:

– Әй, Сәләбә, сиңа нәрсә булды? Син нигә монафыйкларны кабатлый башладың?

– Әй, Аллаһның илчесе! Мин бик ярлы. Хәтта син уйлаганнан да ярлырак. Мин ошбу күлмәкне киям һәм намаз укыйм. Шул вакыт хатыным көтеп тора. Намазны тәмамлагач мин күлмәкне салам һәм хатыныма бирәм. Ул намаз укый. Әй, Аллаһның рәсүле! Миңа байлык теләп дога кылсаң иде.

– Әй, Сәләбә, бу уеңнан кайт. Син шөкер итә торган байлык күп байлыктан хәерлерәк һәм син аңа шөкер итә алмаячаксың

Күмпедер вакыт узгач Сәләбә үтенечен кабатлады. Бу юлы Аллаһ рәсүле аңа болай диде: “Син миңа охшарга тырышмыйсыңмыни? Мин шуны беләм: дөнья бәхете ахирәттән буш калучылар өчен генә. Акылы булмаган кеше генә дөнья тормышы белән алданыр.”

Күпмедер вакыт узгач Сәләбә пәйгамбәребез (с.г.в.) янына кабат килде һәм әйтте: “Әй, Аллаһның илчесе, Аллаһ белән ант итәм, син миңа дога кылсаң мин малымны моңа лаек һәр кешегә таратыр идем.”

Сәләбәнең бертуктаусыз үтенечләренә җавап итеп пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дип дога кылды: “Йә, Раббым Аллаһ, Сәләбәгә байлык бир!” Бу сүзләрне өч мәртәбә кабатлады.

Догадан соң Сәләбә бер сарык сатып алды. Тора-бара аның сарыклары күп булып үрчеде. Хәтта шуңа барып җитте ки: Сәләбә сарыклары Мәдинә урамына сыймый башлады. Ул көтүен көтүлеккә күчерде. Һәм шуның аркасында биш вакыт намаз укуны ташлады. Ә сарыклары тагын да күбәйде һәм аларга инде берничә көтүлек кирәк булды. Сәләбә Мәдинәдән ераклашты. Хәтта ул җомга намазына да йөрүдән туктады.

Бер көнне пәйгамбәребез (с.г.в.) сәхәбәләрдән сорады:

– Сәләбә кайда? Мин аны күрмим?

Сәхәбәләр әйттеләр:

– Әй Аллаһның илчесе! Аның малы күбәйде, ул хәзер бер көтүлеккә генә сыймый, шуңа күрә ерак көтүлекләргә китәргә мәҗбүр булды.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте:

– Сәләбәгә кайгы булсын!

Шуннан соң зәкят түләргә әмер биргән түбәндәге аять иңде: “Аларның малларыннан садака ал, аларны шуның белән пакъларсың һәм сафларсың. Алар өчен дога кыл. Синең догаң алар өчен тынычлану бит” (9:103).

# 2017 елның II яртыеллыгына газетабызга язылу йомгаклары

### I графа – район, өлкә, республика; II – язылучылар саны; 2017 елның I яртыеллыгы белән чагыштырганда арткан (+) яки кимегән (-)

**Татарстан буенча**

| I | II | |
|---|---|---|
| Әгерҗе | 12 | + 3 |
| Азнакай | 10 | - 6 |
| Аксубай | 12 | - 3 |
| Актаныш | 10 | + 1 |
| Әлки | 14 | + 4 |
| Әлмәт | 4 | - 5 |
| Апас | 1 | |
| Арча | 15 | - 4 |
| Әтнә | 1 | - 1 |
| Баулы | 5 | + 1 |
| Балтач | 5 | - 4 |
| Бөгелмә | 1 | |
| Буа | 1 | - 3 |
| Югары Ослан | 7 | + 6 |
| Биектау | 2 | - 3 |
| Алабуга | 7 | |
| Зәй | 25 | |
| Яшел Үзән | 3 | - 7 |
| Кайбыч | 1 | - 3 |
| Кама Тамагы | 2 | + 1 |
| Кукмара | 4 | - 12 |
| Лениногорск | 10 | + 14 |
| Мамадыш | 15 | + 1 |
| Минзәлә | 19 | - 5 |
| Мөслим | 16 | |
| Түбән Кама | 3 | + 2 |
| Яңа Чишмә | 1 | - 2 |
| Норлат | 4 | - 3 |
| Питрәч | 4 | - 1 |
| Балык Бистәсе | 3 | - 4 |
| Саба | 7 | - 7 |
| Сарман | 32 | - 10 |
| Тәтеш | 3 | + 2 |
| Чаллы | 304 | - 32 |
| Чирмешән | 1 | - 12 |
| Чистай | 6 | - 1 |
| Чүпрәле | 10 | - 8 |
| Урыссу | 4 | + 2 |
| Теләче | 3 | - 1 |
| Тәтеш | 1 | |
| Казан | 6 | - 6 |
| **Җәмгысе** | **580** | **-145** |

**Татарстаннан читтә**

| I | II | |
|---|---|---|
| Башкортостан | 129 | - 25 |
| Нижний Новгород | 8 | - 20 |
| Киров | 13 | - 5 |
| Курган | 2 | |
| Пенза | 4 | + 1 |
| Пермь | 9 | 22 |
| Самара | 2 | - 2 |
| Свердловск | 5 | + 1 |
| Саратов | 1 | |
| Омск | 8 | + 1 |
| Орлов | 1 | |
| Оренбург | 14 | - 3 |
| Чувашстан | 4 | - 3 |
| Чиләбе | 6 | - 2 |
| Удмуртия | 1 | |
| Ульяновск | 3 | - 5 |
| Мордовия | 1 | |
| Мәскәү | 1 | - 1 |
| Мәскәү өлкәсе | 1 | |
| Ингушетия | 1 | |
| **Җәмгысе** | **211** | **- 84** |

**Башкортостан буенча**

| I | II | |
|---|---|---|
| Уфа | 5 | + 1 |
| Толбазы | 4 | + 3 |
| Раевка | 2 | - 2 |
| Бирск | 1 | |
| Бүздәк | 2 | |
| Борай | 22 | - 5 |
| Мәсәгут | 15 | - 1 |
| Дәүләкән | 5 | |
| Иглин | 3 | |
| Караидел | 3 | + 1 |
| Кырмыскалы | 25 | - 3 |
| Туймазы | 6 | - 6 |
| Чакмагыш | 13 | - 2 |
| Янаул | 6 | - 1 |
| Стәрлетамак | 7 | - 7 |
| Мәләүз | 4 | - 3 |
| Күмертау | 1 | - 1 |
| Сибай | 1 | + 1 |

# Намаз вакытлары

| Милади Август | Көн исеме | Зөлкагыйдә, Зөлхиҗҗә | Иртәнге намаз: Таң беленә | | | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | | | Кояш чыга | | | Зәвал | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ясту | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Сш | 9 | 03.24 | 01.34 | 01.47 | 03.54 | 02.04 | 02.17 | 05.24 | 03.34 | 03.47 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.44 | 17.00 | 17.14 | 21.18 | 19.37 | 19.51 | 22.48 | 21.07 | 21.21 |
| 2 | Чш | 10 | 03.26 | 01.36 | 01.49 | 03.56 | 02.06 | 02.19 | 05.26 | 03.36 | 03.49 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.43 | 16.59 | 17.12 | 21.16 | 19.35 | 19.49 | 22.46 | 21.05 | 21.19 |
| 3 | Пж | 11 | 03.27 | 01.38 | 01.51 | 03.57 | 02.08 | 02.21 | 05.27 | 03.38 | 03.51 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.42 | 16.58 | 17.11 | 21.14 | 19.33 | 19.47 | 22.44 | 21.03 | 21.17 |
| 4 | Жм | 12 | 03.29 | 01.40 | 01.52 | 03.59 | 02.10 | 02.22 | 05.29 | 03.40 | 03.52 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.41 | 16.57 | 17.10 | 21.12 | 19.31 | 19.45 | 23.42 | 21.01 | 21.15 |
| 5 | Шм | 13 | 01.32 | 01.41 | 01.54 | 04.01 | 02.11 | 02.24 | 05.31 | 03.41 | 03.54 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.39 | 16.56 | 17.09 | 21.10 | 19.29 | 19.42 | 23.38 | 20.59 | 21.12 |
| 6 | Як | 14 | 01.53 | 01.43 | 01.56 | 04.03 | 02.13 | 02.26 | 05.33 | 03.43 | 03.56 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.38 | 16.54 | 17.07 | 21.08 | 19.27 | 19.40 | 23.34 | 20.57 | 21.10 |
| 7 | Дш | 15 | 02.04 | 01.45 | 01.58 | 04.04 | 02.15 | 02.28 | 05.34 | 03.45 | 03.58 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.37 | 16.53 | 17.06 | 21.06 | 19.25 | 19.38 | 23.30 | 20.55 | 21.08 |
| 8 | Сш | 16 | 02.13 | 01.47 | 02.00 | 04.06 | 02.17 | 02.30 | 05.36 | 03.47 | 04.00 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.36 | 16.51 | 17.05 | 21.04 | 19.23 | 19.36 | 23.26 | 21.53 | 22.06 |
| 9 | Чш | 17 | 02.21 | 00.02 | 00.13 | 04.08 | 02.19 | 02.32 | 05.38 | 03.49 | 04.02 | 13.19 | 11.35 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.34 | 16.50 | 17.03 | 21.02 | 19.21 | 19.34 | 23.21 | 21.48 | 22.02 |
| 10 | Пж | 18 | 02.28 | 00.16 | 00.28 | 04.10 | 02.21 | 02.34 | 05.40 | 03.51 | 04.04 | 13.20 | 11.35 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.33 | 16.49 | 17.02 | 21.00 | 19.18 | 19.32 | 23.18 | 21.44 | 21.57 |
| 11 | Жм | 19 | 02.34 | 00.26 | 00.38 | 04.12 | 02.23 | 02.36 | 05.42 | 03.53 | 04.06 | 13.18 | 11.35 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.31 | 16.47 | 17.00 | 20.58 | 19.16 | 19.29 | 23.14 | 21.39 | 21.53 |
| 12 | Шм | 20 | 02.40 | 00.35 | 00.47 | 04.14 | 02.25 | 02.38 | 05.44 | 03.55 | 04.08 | 13.18 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.30 | 16.46 | 16.59 | 20.56 | 19.14 | 19.27 | 23.10 | 21.35 | 21.49 |
| 13 | Як | 21 | 02.46 | 00.42 | 00.54 | 04.15 | 02.27 | 02.40 | 05.45 | 03.57 | 04.10 | 13.18 | 11.35 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.29 | 16.44 | 16.57 | 20.54 | 19.12 | 19.25 | 23.06 | 21.31 | 21.44 |
| 14 | Дш | 22 | 02.52 | 00.49 | 01.01 | 04.17 | 02.29 | 02.42 | 05.47 | 03.59 | 04.12 | 13.18 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.27 | 16.43 | 16.56 | 20.51 | 19.09 | 19.23 | 23.02 | 21.27 | 21.40 |
| 15 | Сш | 23 | 02.56 | 00.55 | 01.07 | 04.19 | 02.31 | 02.44 | 05.49 | 04.01 | 04.14 | 13.17 | 11.34 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.26 | 16.41 | 16.54 | 20.49 | 19.07 | 19.20 | 22.58 | 21.23 | 21.36 |
| 16 | Чш | 24 | 03.01 | 01.01 | 01.13 | 04.21 | 02.32 | 02.45 | 05.51 | 04.02 | 04.15 | 13.17 | 11.34 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.24 | 16.39 | 16.53 | 20.47 | 19.05 | 19.18 | 22.55 | 21.19 | 21.32 |
| 17 | Пж | 25 | 03.05 | 01.06 | 01.19 | 04.23 | 02.34 | 02.47 | 05.53 | 04.04 | 04.17 | 13.17 | 11.34 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.22 | 16.38 | 16.51 | 20.45 | 19.02 | 19.16 | 22.51 | 21.15 | 21.28 |
| 18 | Жм | 26 | 03.10 | 01.11 | 01.24 | 04.25 | 02.36 | 02.49 | 05.55 | 04.06 | 04.19 | 13.17 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.21 | 16.36 | 16.49 | 20.42 | 19.00 | 19.13 | 22.48 | 21.11 | 21.24 |
| 19 | Шм | 27 | 03.14 | 01.16 | 01.29 | 04.27 | 02.38 | 02.51 | 05.57 | 04.08 | 04.21 | 13.17 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.19 | 16.35 | 16.48 | 20.40 | 18.58 | 19.11 | 22.44 | 21.07 | 21.20 |
| 20 | Як | 28 | 03.18 | 01.21 | 01.34 | 04.28 | 02.40 | 02.53 | 05.58 | 04.10 | 04.23 | 13.16 | 11.33 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.18 | 16.33 | 16.46 | 20.38 | 18.55 | 19.08 | 22.40 | 21.03 | 21.16 |
| 21 | Дш | 29 | 03.22 | 01.26 | 01.38 | 04.30 | 02.42 | 02.55 | 06.00 | 04.12 | 04.25 | 13.16 | 11.33 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.16 | 16.31 | 16.44 | 20.35 | 18.53 | 19.06 | 22.37 | 20.59 | 21.13 |
| 22 | Сш | 30 | 03.26 | 01.30 | 01.43 | 04.32 | 02.44 | 02.57 | 06.02 | 04.14 | 04.27 | 13.16 | 11.33 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.14 | 16.29 | 16.43 | 20.33 | 18.50 | 19.04 | 22.33 | 20.56 | 21.09 |
| 23 | Чш | 1 | 03.30 | 01.34 | 01.47 | 04.34 | 02.46 | 02.59 | 06.04 | 04.16 | 04.29 | 13.16 | 11.33 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.13 | 16.28 | 16.41 | 20.31 | 18.48 | 19.01 | 22.30 | 20.52 | 21.05 |
| 24 | Пж | 2 | 03.33 | 01.38 | 01.51 | 04.36 | 02.48 | 03.01 | 06.06 | 04.18 | 04.31 | 13.16 | 11.32 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.11 | 16.26 | 16.39 | 20.28 | 18.45 | 18.59 | 22.27 | 20.48 | 21.02 |
| 25 | Жм | 3 | 03.37 | 01.42 | 01.55 | 04.38 | 02.50 | 03.03 | 06.08 | 04.20 | 04.33 | 13.16 | 11.32 | 11.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.09 | 16.24 | 16.37 | 20.26 | 18.43 | 18.56 | 22.23 | 20.45 | 20.58 |
| 26 | Шм | 4 | 03.40 | 01.46 | 01.59 | 04.40 | 02.52 | 03.05 | 06.10 | 04.22 | 04.35 | 13.16 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.07 | 16.22 | 16.35 | 20.24 | 18.40 | 18.54 | 22.20 | 20.41 | 20.54 |
| 27 | Як | 5 | 03.44 | 01.50 | 02.03 | 04.41 | 02.54 | 03.07 | 06.11 | 04.24 | 04.37 | 13.16 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.05 | 16.20 | 16.34 | 20.21 | 18.38 | 18.51 | 22.16 | 20.37 | 20.51 |
| 28 | Дш | 6 | 03.47 | 01.54 | 02.06 | 04.43 | 02.56 | 03.09 | 06.13 | 04.26 | 04.39 | 13.15 | 11.31 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.04 | 16.19 | 16.32 | 20.19 | 18.35 | 18.49 | 22.13 | 20.34 | 20.47 |
| 29 | Сш | 7 | 03.50 | 01.57 | 02.10 | 04.45 | 02.58 | 03.11 | 06.15 | 04.28 | 04.41 | 13.15 | 11.31 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.02 | 16.17 | 16.30 | 20.16 | 18.33 | 18.46 | 22.10 | 20.30 | 20.44 |
| 30 | Чш | 8 | 03.54 | 02.01 | 02.13 | 04.47 | 03.00 | 03.13 | 06.17 | 04.30 | 04.43 | 13.15 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.00 | 16.15 | 16.28 | 20.14 | 18.30 | 18.44 | 22.07 | 20.27 | 20.40 |
| 31 | Пж | 9 | 03.57 | 02.04 | 02.17 | 04.49 | 03.02 | 03.15 | 06.19 | 04.32 | 04.45 | 13.15 | 11.30 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.58 | 16.13 | 16.26 | 20.11 | 18.28 | 18.41 | 22.03 | 20.24 | 20.37 |

## Дини культурабыз җитми

Күңелне борчып торган, эчне пошырган кайбер нәрсәләрне мөселман кардәшләргә дә җиткерергә телим. Чөнки мөселман кеше кимчелек күрсә аны төзәтергә, ә көче җитмәсә күңеленнән булса да риза булмаска тиеш.

"ТНВ" каналында җомга көн тапшыруын карадым. Андагы әңгәмәдә амулетлар турында сүз барды. Әңгәмәдәшләрнең ислам буенча гыйлемнәре бик чамалы икәне күренә иде. Киенешләре дә шәригать таләпләренә туры килми. Болай эшләү мөселман тамашачысын хөрмәт итмәү булмыймы икән?

Икенчесе — мөслимәләр безнең шартларга туры килми торган чамасыз озын хиҗаблар кия башладылар. Шул сәбәпле урамнан барганда, автобуска менгәндә, тәшкәндә бар пычракны үзләренә ияртәләр. Аннары мәчеткә кереп намазга басалар. Ислам чисталык дине. Моны ничек аңларга?

Динебезнең каршы җенескә охшарга тырышуын хупламавын белә торып мәчеткә чалбар киеп килүче хатын-кызларыбыз да җитәрлек. Гомумән, мөслимәләргә намазларны өйләрендә уку хәерлерәк булыр иде. Алар мәчетләрдә ир-атлар белән аралашырга тиеш түгел. Чаллының "Тәүбә", "Нур-Ихлас", "Сөембикә", "Рамазан" мәчетләрендә хатын-кызлар өчен аерым керү урыннары булдырылган. Аларны башка мәчетләрдә дә булдыру кирәк.

Минемчә, халыкны дини культурага өйрәтү өчен бу темага күбрәк вәгазьләр сөйләү, әңгәмәләр алып бару таләп ителә. Әйтик, шул ук мәчеткә ялан аяк, яланбаш керү, урындыкларда алгы сафта утырып уку, намаз вакытында мәчеткә телефоннан шалтырату, кесә телефоннарын сүндермәү һ.б.лар да дини культураның җитмәвен күрсәтүче мисаллар.

**Рәфыйк**
**Чаллы шәһәре.**

### Танышырга телим

Чаллыда яшәүче 57 яшьлек ялгыз мөэминә бер гаилә булып яшәү өчен тәртипле татар кешесе белән никахлашырга тели. Яшәү урыны бар. Тел. 89179299084.

* * *

Чаллыда үз фатиры белән яшәүче 75 яшьлек ялгыз мөэминә картлыкта терәк була алырлык ялгыз мөселман кешесе белән никахлашырга тели. Тел. (8552) 42-89-72

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 7 июль 16 сәг. фактта 7 июль 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**